ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.02.2021 Казан шәһәре № 30

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2018 елның 11 июлендәге 70 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында»гы Федераль законның 22 һәм 48 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 346-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмә раслау турында» 2018 елның 11 июлендәге 70 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2020 елның 29 апрелендәге 52 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 127 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш бүлегеннән дә – Дәүләт комитетында кадрлар белән эшчәнлек оештыру һәм аны алып бару өчен җаваплы булган затлар, вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган Дәүләт комитеты структур бүлекчә-

сеннән (кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган Дәүләт комитеты бүлекчәсеннән)), Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитеты рәисенең рәсми мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Президенты каршын-дагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакыртыла торган, кадр технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча бәйсез экспертлар – тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәтенең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә белгечләр булып торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.

Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.».

Рәис С.Е. Иванов